

***<u>Мусина Ильсия Мавлетовна, воспитатель первой квалификационной категории:</u>***

“Мин беренче балалар бакчасына 1988 елның 1 декаберендә эшкә килдем. Ул елларда безнең бакчада 6 яшьлек балаларны җыеп, 1 класс оештырып, мәктәптән укытучылар килеп укыта иде. Төштән соң алар бакча режимында укып-уйнап, тәрбия алдылар. Бер елдан соң без аларны үзләренең укытучылары белән мәктәпкә озата идек. Ике ел шул төркем балар белән эшләгәннән соң, төрле группаларда эшләдем.

Бакча мөдире Сания Тагировна мине һәм тәрбияче ярдәмчесе Венера Рафаэловна белән 2-3 яшькә кадәр балалар белән эшләргә куйды. Лаеклы ялга киткәнче мин шул балаларны тәрбияләдем.

Бакча коллективының дус-тату, бер-берсенә булышып, ярдәм итеп эшләү дәверендә мин бик өйрәндем, тәҗрибә тупладым. Шул елларда үземнең остазым итеп, Алсу Разимовнаны санийм. Аның һәм күп өлкән яшьтәге тәрбиячеләрнең ярдәмен тоеп эшләдем. Тәрбияче булып эшләгән дәвердә, мин әти-әниләр белән тыгыз элемтәдә тордым. Балаларның телен ачуда, күңелләрен күтәрүдә алар өчен беренче дәрәҗәдә кирәкле-ул балалар фольклорын сайлап алдым. Бу фольклор аларның үз зәвыкларына корылган. Шунлыктан безнең балалар татар халык уеннарын, әйтемнәрен, юаткычларын, әкиятләрен, такмакларын яратып өйрәнделәр. Балаларның сәләтен, сүз байлыгын, сөйләмен ана телендә үстерү өстендә эшләдем.

Әти-әниләр белән бергәләп белем бирү бурычын куйдым. Бу эштә миңа Альмухаметов Алмазның әнисе, Мирсаяпова Әдиләнең әнисе, Хусаинова Наиләнең әбисе белән бабасы, Закирова

Ильвинаның әнисе, Богатырёва Иделиянең әбисенең һәм башка бик күп әниләрнең ярдәмен тоеп эшләдем, һәм мин аларга бик рәхмәтлемен. Эшләү дәверендә , үземнең эш тәҗрибәм белән дә уртаклаштым, эшләремне “Тәрбия”һәм “Ачык дәрес”газеталарына бастырып чыгардылар.

Без музыка белгече Людмила Геннадиевна белән күп еллар бергә балалар белән бәйрәм чараларын, район тәрбиячеләренә, әти-әниләргә һәм үзебезнең бакча тәрбиячеләренә күрсәттек.

Эшемне күреп бәяли белделәр, әти-әниләрдән рәхмәт хатлары һәм җитәкчеләрдән күп санлы мактау грамоталары алдым.

Әзер без инде лаеклы ялда булсакта, бакча мөдире Гульнара Ринатовна, тәрбияче кызлар бик ихтирам итәләр,ачык йөз белән каршы алалар....”